ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**05.03.2019**

Зеленодольск
шәһ.

**КАРАР**
**№553**

Зеленодольск муниципаль районы территориясендә гадәттән тыш хәлләрдә җәмәгать тәртибен саклау турында

1994 елның 21 декабрендәге «Халыкны һәм территорияне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» №68-ФЗ Федераль законга ярашлы рәвештә, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» №131-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2003 елның 30 декабрендәге «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм юкка чыгару бердәм дәүләт системасы турында» 794нче карары белән, Зеленодольск муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характерда гадәттән тыш хәлләр чыкканда җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү максатыннан Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРА ИТӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр чыкканда җәмәгать тәртибен саклауны оештыру тәртибен кушымтага ярашлы раслау.
2. ЯҮМР Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм информация чаралары белән элемтә бүлеге җитәкчесе Д.С.Анисимовка әлеге карарны массакүләм информация чараларында бастырып чыгаруны, Интернет челтәрендәге хокукый информация рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр порталы составында Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштыруны тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольгә алуны үземдә калдырам.

Җитәкче Д.А. Сапожников

Зеленодольск муниципаль
районы
Башкарма комитетының
2019 елның
5 мартындагы 553нче
Карарына кушымта

Зеленодольск муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда җәмәгать тәртибен саклауны оештыру тәртибе

1. Әлеге Тәртип Зеленодольск муниципаль районында табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда җәмәгать тәртибен һәм юл хәрәкәте иминлеген, пропуск режимын, матди һәм мәдәни байлыкларны саклауны тәэмин итүнең максатларын, бурычларын, тәртибен билгели.

2. Гадәттән тыш хәлләрдә җәмәгать тәртибен булдыру Зеленодольск муниципаль районы территориясендә Зеленодольск гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм юкка чыгару территориаль подсистемасы звеносы (алда – ЗЗТСЧС) гамәлдә булуы кысасында алып барыла.

3. Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда җәмәгать тәртибен һәм юл хәрәкәте иминлеген, пропуск режимын, матди һәм мәдәни байлыкларны саклауны тәэмин итү буенча бурычларны үтәү һәм шулай ук гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда халык арасында паниканы кисәтү һәм юкка чыгару өчен Зеленодольск районы буенча Россия МВДсы бүлеге, Зеленодольск районы буенча «Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләренең ведомстводан тыш идарәсе» (Росгвардия) ФГКУ филиалы көчләре һәм әйберләре җәлеп ителә.

4. Гадәттән тыш хәлләрне юкка чыгарганда эчке эшләр, ведомстводан тыш сак органнарының көчләре һәм әйберләре Россия Федерациясе законнары һәм башка норматив һәм хокукый актлары белән йөкләнгән бурычларга ярашлы кулланыла.

5. Гадәттән тыш хәлләрдә җәмәгать тәртибен саклауның төп бурычларына керә:

– Зеленодольск муниципаль районы территориясендә чыккан гадәттән тыш хәлләр, аварияләр турында халыкка көчле сөйли торган элемтә белән җиһазландырылган транспорт чаралары кулланып хәбәр итү ;

– җәмәгать тәртибен, матди һәм мәдәни байлыкларны саклау, пропуск режимын оештыруны тәэмин итү өчен хәлне бәяләү һәм кирәкле көчләрне һәм әйберләрне билгеләү;

– гадәттән тыш хәл зонасына пропуск режимын кертү;

– гадәттән тыш хәл чыккан урыннан зыян күргән затларны чыгару өчен җәмәгать һәм шәхси транспортны җәлеп итү;

– транспорт чаралары һәм җәяүлеләр хәрәкәтен көйләү;

– паниканы һәм массакүләм тәртипсезлекләрне булдырмау;

– халыкны куркыныч зоналардан, биналардан, корылмалардан эвакуацияләүне тәэмин итү;

– авария, катастрофа урынына коткару һәм авария-техник көчләрне каршылыксыз кертүне тәэмин итү;

– матди байлыкларны урлау очракларын булдырмау, җәмәгать тәртибен тәэмин итү;

– куелган бурычларны үтәү өчен карарларны вакытында кабул итү өчен хәл үсешен фаразлау.

6. Зеленодольск районы буенча Россия МВДсының бүлеге, Зеленодольск районы буенча «Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләренең ведомстводан тыш идарәсе» (Росгвардия) ФГКУ филиалының бүлекчәләре, хезмәтләре һәм хәрби тәртип төркемнәре эшләре идарәсен һәм координацияләүне тәэмин итү максатыннан һәм шәһәр ЗТСЧСының идарә органнары белән элемтәсен булдыру өчен Зеленодольск муниципаль районының гадәттән тыш хәлләр һәм янгын куркынычсызлыгын булдыруны тәэмин итү Комиссиясе карары белән җәмәгать тәртибен саклау буенча оператив штаб төзелә.

7. Җәмәгать тәртибен саклау оператив штабы гадәттән тыш хәл чыккан зонада булган халык һәм оешмалар гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда җәмәгать тәртибен булдыру өчен үтәргә тиешле бурычларын билгеләгән карарлар чыгара.

8. Гадәттән тыш хәлне юкка чыгаруга җәлеп ителгән бөтен көчләр һәм әйберләргә, алар арасында элемтә булдыруга, шул исәптән җәмәгать тәртибен саклауга гадәттән тыш хәлне юкка чыгару җитәкчесе җитәкчелек итә

9. Гадәттән тыш хәлне юкка чыгару җитәкчесе Зеленодольск муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм юкка чыгару, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча Комиссия рәисе күрсәтмәсе белән билгеләнә.